**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул. Московская, 2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ БИТАМАН**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

422755, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**30 ноябрь 2023 г.** **№ 9**

**Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1., 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставының 24 статьясы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2019 елның 23 октябрендәге 150 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе" нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 12 декабрендә 18.00 сәг Олы Битаман авылы, Мәскәү урамы, 2В адресы буенча (мәдәният йортында) Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Олы Битаман торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына түбәндәге сорауларны куярга:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Олы Битаман торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үз-үзенә салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) Юлларны кышын һәм җәен төзекләндереп тору (тракторчыга хезмәт хакы, ЯММ сатып алу)
2) зират коймасына матриаллар сатып алу
3) зират коймасын кору
4) чүплекне бетерү

“РИЗА” "КАРШЫ".

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм республиканың рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге кара халыкка җиткерелгеннән көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Ф.Ю.Закиров